**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 34-6 «24» февраль 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында

Татарстан Республикасының 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Законының 14 статьясының 1нче өлеше нигезендә,

Азнакай район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитетын административ комиссия төзүгә вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

2. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетына:

- Азнакай муниципаль районының административ комиссиясен төзергә;
- Азнакай муниципаль районының административ комиссиясе составын расларга;
- Азнакай муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламентын расларга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә :http://aznakayevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга.

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Азнакай район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләнә.

Рәис М. З. Шәйдуллин